ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.06.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1513**

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта) расларга.
2. «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчаларын) гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны кертү һәм исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 маендагы 931 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары- мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### I. Гомуми нигезләмәләр

### Административ регламентны җайга салу предметы

«Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба - Административ регламент) муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыру максатларында эшләнде, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм юнәлдерү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда гамәлләрнең (административ процедураларның) стандартын, срокларын һәм эзлеклелеген билгели. Әлеге административ регламент «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты, 2 өлеше, 67 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

### Мөрәҗәгать итүчеләр даирәсе

1.1. Муниципаль хезмәт алуга мөрәҗәгать итүче булып баланың ата-анасы (законлы вәкиле) тора (алга таба - мөрәҗәгать итүче).

1.2. Муниципаль хезмәт алуга мөрәҗәгать итүче булып «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында теркәү процедурасын үтүне тәгәлләгән, «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба - ЕПГУ) (https://www.gosuslugi.ru/) һәм/ яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) региональ порталлары (алга таба - РПГУ) аша , баланың ата-анасы (законлы вәкиле) тора.

### Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү тәртибенә карата таләпләр

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) мөрәҗәгать итүчене Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (алга таба - Вәкаләтле орган) турыдан-туры шәхсән кабул иткәндә, яисә күпфункцияле үзәк һәм Вәкаләтле орган арасында төзелгән килешү нигезендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - күпфункцияле үзәк) .

2) Вәкаләтле органда яисә күпфункцияле үзәктә телефон аша ;

3) язмача, шул исәптән электрон почта, гомуми файдаланудагы почта элемтәсе (алга таба - почта элемтәсе) ярдәмендә;

4) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүматның ачык һәм һәркем файдалана алырлык формасында урнаштыру юлы белән:

ЕПГУ һәм/ яки РПГУ да;

Вәкаләтле органның *https://edu.tatar.ru* рәсми сайтында

5) Вәкаләтле органның яисә күпфункцияле үзәкнең мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру юлы белән.

1.4. Мәгълүмат бирү түбәндәге кагылышлы мәсьәләләр буенча гамәлгә ашырыла:

муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү ысулларына;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган Вәкаләтле орган һәм күпфункцияле үзәкләр адресларына;

Вәкаләтле органның (Вәкаләтле органның структур бүлекчәләренең) һәм күпфункцияле үзәкләрнең эше турында белешмә мәгълүматка;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт күрсәтү һәм хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документларга; муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм срокларына;

муниципаль хезмәт күрсәтү турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында гаризаны карау барышы хакында белешмәләр алу тәртибенә;

вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү һәм алар тарафыннан кабул ителә торган карарларга муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә шикаять белдерү тәртибенә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат алу түләүсез гамәлгә ашырыла.

1.5. Мөрәҗәгать итүче телдән (шәхсән яисә телефон буенча)мөрәҗәгать иткәндә консультация бирүне гамәлгә ашыручы Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчеләргә кызыксындырган мәсьәләләр буенча җентекләп һәм әдәпле (корректлы) рәвештә мәгълүмат бирә.

Телефоннан шалтыратуга җавап мөрәҗәгать итүче шалтыраткан органның исеме һәм телефон шалтыратуын кабул иткән белгечнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), вазифасы турындагы мәгълүматтан башлана.

Әгәр Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөстәкыйль рәвештә җавап бирә алмаса, телефон шалтыравы башка вазыйфаи затка адресланган (күчерелгән) яисә мөрәҗәгать иткән затка тиешле мәгълүмат алырга мөмкин булган телефон номеры хәбәр ителергә тиеш.

Әгәр җавап әзерләү озак вакыт таләп итсә, ул мөрәҗәгать итүчегә алдагы гамәлләрнең түбәндәге вариантларын тәкъдим итә:

мөрәҗәгатьне язма рәвештә бәян итәргә һәм Вәкаләтле органның, күпфункцияле үзәкнең электрон почтасы аша яисә почта элемтәсе аша җибәрергә;

консультацияләр өчен башка вакыт билгеләргә;

шәхсән килергә.

Вәкаләтле органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандарт процедуралары һәм шартлары кысаларыннан чыга торган һәм кабул ителә торган карарга турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясый торган мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырырга хокуклы түгел.

Телефон буенча мәгълүмат җиткерү 10 минуттан да артмаска тиеш.

Мәгълүмат бирү гражданнарны кабул итү графигы нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.6. Язма мөрәҗәгате буенча Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре 2006 елның 2 маендагы«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, әлеге Административ регламентның 1.4 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча гражданга язма рәвештә җентекләп аңлатма бирә.

1.7. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карары белән расланган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә каралган белешмәләр ЕПГУ да урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе һәм документлар турындагы мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән, мөрәҗәгать итүченең техник чараларына җайланмасын урнаштыру мөрәҗәгать итүченең техник чараларына түләүне алуны, теркәүне яисә авторизацияне яки аларга шәхси мәгълүматларны бирүне күздә тотучы программа белән тәэмин итүнең хокукый хуҗасы белән лицензияле яисә башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

1.8. Вәкаләтле органның рәсми сайтында, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр һәм муниципаль хезмәт күрсәтү урыннарындагы стендларда һәм күпфункцияле үзәктә түбәндәге белешмә урнаштырыла:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы Вәкаләтле органның һәм аның структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында; муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы Вәкаләтле органның структур бүлекчәләренең, шулай ук күпфункцияле үзәкләрнең белешмә телефоннары, шул исәптән автоинформатор телефоны номеры (булган очракта) турында; рәсми сайт адресы, шулай ук электрон почта һәм (яисә) Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге кире элемтә формасы.

1.9. Вәкаләтле органның көтү залларында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар, шул исәптән мөрәҗәгать итүче таләбе буенча аңа танышу өчен бирелә торган Административ регламент урнаштырыла.

1.10. Күпфункцияле үзәк бинасында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштыру, Административ регламентта билгеләнгән мәгълүмат бирүгә таләпләрне исәпкә алып, күпфункцияле үзәк һәм Вәкаләтле орган арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.11. Гаризаны карау барышы турында муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ЕПГУ һәм/яки РПГУ дагы шәхси кабинетында, шулай ук Вәкаләтле органның тиешле структур бүлекчәсендә, күпфункцияле үзәкләрдә, мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә телефон аша, электрон почта яисә почта элемтәсе аша алынырга мөмкин.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты
## Муниципаль хезмәт исеме

**2.1. «Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм юнәлдерү» муниципаль хезмәт күрсәтү.**

### Муниципаль хезмәт күрсәтз торган дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы (оешма) исеме

2.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең Вәкаләтле органы тарафыннан күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе урнашкан урын: ТР, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 38 й.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе эш графигы: дүшәмбе - җомга, 8.00 - 17.00 сәгатьләрдә, төшке ашка тәнәфес 12.00 - 13.00 сәгатьләрдә

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белешмә телефоннары: кабул итү бүлмәсе 8(84371)4-34-30, «Электрон балалар бакчасы» АИС өчен җаваплы 8(84371)4-97-53.

2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә 10 нчы кушымтада күрсәтелгән оешмалар катнаша

Муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә Вәкаләтле орган түбәндәгеләр белән үзара бәйләнештә :

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең, мәгълүмат технологияләренең һәм элемтәсенең цифрлы үсеш министрлыгы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә Вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр исемлегенә кертелгән хезмәт күрсәтүләрне алганнан тыш, башка дәүләт органнарына һәм оешмаларга мөрәҗәгать итү белән бәйле гамәлләр, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәк булган килешүләрне гамәлгә ашыруны таләп итү тыела.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы**

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе: муниципаль мәгариф оешмасында урын бирү өчен мохтаҗларны исәпкә кую (арадаш нәтиҗә) һәм муниципаль мәгариф оешмасына юнәлтү (төп нәтиҗә).

2.5.1. Әлеге Административ регламентка 1 нче һәм 2 нче кушымтагы форма буенча Арадаш нәтиҗә өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар

2.5.2. Әлеге Административ регламентка 3 нче һәм 4 нче кушымтагы форма буенча Төп нәтиҗә өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар

2.5.3. Әлеге административ регламентка 5 нче һәм 6 нчы кушымтадагы форма буенча Арадаш нәтиҗә – исәпкә кую өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар

**Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы**

2.6. Вәкаләтле орган, Вәкаләтле органда муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны теркәгән көннән алып 7 эш көне эчендә, мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән яисә, гаризаны электрон рәвештә биргән очракта, ЕПГУ һәм/яки РПГУ дагы шәхси кабинетына җибәрү юлы белән , Административ регламентның 2.5.1 яисә 2.5.3 пунктларында күрсәтелгән нәтиҗәләрне җибәрә.

Вәкаләтле орган, гаризада күрсәтелгән кабул итү датасын исәпкә алып, муниципаль оешмада урын бирү турындагы документ расланганнан соң, 1 көн эчендә мөрәҗәгать итүчегә Административ регламентның 2.5.2 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәне җибәрә.

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар**

2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган түбәндәге норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, ЕПГУ һәм/яки РПГУ тиешле бүлекләрдә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең рәсми сайтында урнаштырыла:

2012 елның 29 декабрендәге«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Мәгариф министрлыгының 2020 елның 15 маендагы «Мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алуга кабул итү тәртибен раслау турында» 236 номерлы боерыгы;

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 28 декабрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер оешмадан укучыларны тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерү тәртибен һәм шартларын раслау турында» (ата-ана (законлы вәкил) инициативасы буенча дәүләт яки муниципаль белем бирү оешмасына күчерү өлешендә)1527 номерлы боерыгы;

Россия Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» (аерым төркемнәрдә яки аерым белем бирү оешмаларында балалар саны өлешендә)2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгы ;

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2020 елның 16 июлендәге 1845-р номерлы күрсәтмәсе, Мәскәү;

2013 елның 22 июлендәге«Мәгариф турында» 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 ноябрендәге«Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында» 1039 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләренә территорияләрне беркетү турында» карары (ел саен чыгарыла).

Чиратсыз (беренче чиратта) муниципаль хезмәт күрсәтүгә Федераль законнарда хокук өлешендә каралган:

1992 елның 17 гыйнварындагы «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 2202-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

1992 елның 26 июнендәге«Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

2010 елның 28 декабрендәге«Россия Федерациясе Тикшерү комитеты турында» 403-ФЗ номерлы Федераль закон;

1998 елның 27 маендагы«Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 76-ФЗ номерлы Федераль закон;

2011 елның 7 февралендәге «Полиция турында»3-ФЗ номерлы Федераль закон;

2012 елның 30 декабрендәге «Башкарма хакимиятнең кайбер федераль органнары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 283-ФЗ номерлы Федераль закон; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 9 февралендәге«Россия Федерациясенең Төньяк Кавказ төбәге территориясендә хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүче

федераль башкарма хакимият органнары хезмәткәрләренә һәм хәрби хезмәткәрләргә өстәмә гарантияләр һәм компенсацияләр турында» 65 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1999 елның 25 августындагы «Дагыстан Республикасы территориясендә терроризмга каршы көрәштә турыдан-туры катнашкан һәм һәлак (хәбәрсез югалган), хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә инвалид булган хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары, янгынга каршы дәүләт хезмәте, җинаять-башкарма системасы хезмәткәрләренең гаилә әгъзаларын социаль яклау буенча өстәмә чаралар турында»936 номерлы карары .

1991 елның 15 маендагы «Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы; Россия Федерациясе Югары Советының 1991 елның 27 декабрендәге«Чернобыль АЭС һәлакәте аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль ярдәм турында» РСФСР Законының гамәлдә булуын аеруча куркыныч янаган төркемнәрдәге гражданнарга тарату хакында» 2123-1 номерлы карары;

1992 елның 5 маендагы «Гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 431 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы;

1992 елның 2 октябрендәге «Инвалидларга дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 1157 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы.

«Электрон балалар бакчасы» АИС системасында ташламаларның гамәлдә булу срогы 12 нче кушымтада күрсәтелгән.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның һәм белешмәләрнең тулы исемлеге**

2.8. Муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләрне тапшыра:

2.8.1. Әлеге административ регламентның 7 нче кушымтасында каралганча электрон рәвештә яисә 8 нче кушымтасында каралганча кәгазь саклагычта Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм Административ регламентның 2.8.2-2.8.8 пунктларына ярашлы рәвештә документлар, шул исәптән гаризага беркетелә торган электрон документлар рәвешендә . Гариза ЕПГУ һәм / яки РПДУ аша җибәрелгән очракта, гаризаны формалаштыру ЕПГУ һәм / яки РПГУ дагы интерактив форманы тутыру юлы белән, нинди дә булса башка формада гариза бирү зарурлыгыннан башка, башкарыла.

2.8.2. Мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслый торган документ.

ЕПГУ һәм/ яки РПГУ аша гариза җибәргәндә, кулланучы тарафыннан ЕСИАда учет язмасын булдырганда һәм раслаганда кулланучы тарафыннан күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ турындагы мәгълүматлар тапшырыла. Күрсәтелгән белешмәләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын (СМЭВ)кулланып рәсми мөрәҗәгать җибәрү юлы белән тикшерелергә мөмкин.

2.8.3. Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслый торган документ(-лар), баланың шәхесен таныклый торган һәм бала хокукларын бирүнең законлылыгын раслый торган документ (мөрәҗәгать итүче - чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат өчен).

2.8.4. Опека билгеләүне раслый торган документ (кирәк булганда).

2.8.5. Психологик-медик-педагогик комиссия документлары (кирәк булганда).

2.8.6. Сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемдә өйрәтүгә ихтыяҗны раслый торган документ(кирәк булганда).

2.8.7. Гражданнарның һәм аларның гаиләләренең аерым категорияләренә ярдәм итүнең (гарантияләрнең) махсус чаралары булуын раслый торган документ (кирәк булганда)

2.8.8. Баланың вакытлыча тору урыны, фактта яшәү урыны турында белешмәләрне үз эченә алган документ (беркетелгән территориядә яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык булмаганда).

Кәгазь саклагычта бирелгән гаризада шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен җибәрүнең түбәндәге ысулларының берсе күрсәтелә:

телефон, электрон почта аша хәбәр итү рәвешендә;

Вәкаләтле органда, күп функцияле үзәктә һәм/яки гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелгән электрон документның басма нөсхәсе рәвешендә кәгазь саклагычта.

2.9. Мәгълүмат алу турында гариза ЕПГУ да рәсмиләштергәндә, кәгазь саклагычта җибәрү өчен бирелгән гариза буенча өстәмә рәвештә мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен ЕПГАда алырга мөмкин.

**Муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка органнар һәм оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар һәм белешмәләрнең тулы исемлеге**

2.10. муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка органнар һәм оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документлар һәм белешмәләрнең исемлеге, мөрәҗәгать итү очрагында, түбәндәгеләр:

- Россия Федерациясе территориясендә бирелгән баланың туу турында таныклыгы;
- беркетелгән территориядә яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча баланы теркәү турында таныклык яисә баланың яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча белешмәләр булган документлар.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

2.11.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган документларны тапшыру һәм мәгълүмат бирү яисә гамәлгә ашыру.

2.11.2. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, Зеленодольск муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) ведомство буйсынуындагы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагында булган, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)күрсәтелгән документлардан тыш, муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалардан кирә торган документлар һәм мәгълүмат тапшыру

**Гариза кәгазь саклагычта бирелгәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге**

2.12. Гариза кәгазь саклагычта бирелгәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- әлеге Административ регламентның 2.8 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан кимчелекләрне төзәтү срокларын исәпкә алып, тулы булмаган мәгълүмат (мөрәҗәгать итүчедән документлар комплекты) бирү;
- мөрәҗәгать итүче тарафыннан, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган, текстта бозулар чистартулар һәм төзәтүләр булган документлар тапшыру;

**Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге**

2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.14. Арадаш нәтиҗә - исәпкә кую өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

- мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү хокукына ия затлар категориясенә туры килми;
- әлеге Административ регламентның 2.8 пункты нигезендә дөрес булмаган мәгълүмат бирү;
- тапшырылган документлар яисә белешмәләр муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен мөрәҗәгать итү вакытына үз көчләрен югалткан (мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, күрсәтелгән зат муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта);
- рәсми мөрәҗәгать формасында мәҗбүри кырларны корректлы тутырмау, шул исәптән ЕПГУ дагы рәсми мөрәҗәгать интерактив формасында (дөрес түгел, тулы түгел, яки дөрес тутырмау) (гаризаны электрон рәвештә биргәндә);
- тулы булмаган мәгълүмат бирү, шул исәптән тулы булмаган документлар комплекты *(гаризаны электрон рәвештә биргәндә)*;
- хезмәт күрсәтү турында гариза вәкаләтләренә хезмәт күрсәтү кермәгән дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмаларга бирелгән*(гаризаны кәгазь саклагычта тапшырганда)* .

Төп нәтиҗә - юнәлеш бирү өлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнар һәм оешмалар тарафыннан бирелгән документ (документлар) турында белешмәләр**

2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр юк.

**Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре**

2.16. Муниципаль хезмәт күрсәтү түләүсез .

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп**

2.17. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр юк.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм кәгазь саклагычта гариза биргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен чират көтүнең максималь срогы**

2.18. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм Вәкаләтле органда яисә күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт күрсәтү һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең арадаш нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмый.

**Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада**

2.19. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризалар һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар алынган көннән алып 1 эш көне эчендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Вәкаләтле органда теркәлергә тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, кәгазь саклагычта гариза биргәндә, Вәкаләтле орган җитешсезлекләрне төзәтү өчен билгеләнгән соңгы көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, җитешсезлекләрне төзәтү срогын исәпкә алып, мөрәҗәгать итүчегә әлеге Административ регламентка 9 нчы кушымтада китерелгән форма буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар җибәрә.

**Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга таләпләр**

2.20. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле кәгазь саклагычта гаризалар һәм документлар кабул ителә торган административ биналарның урнашуы, шулай ук кәгазь саклагычта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен бирү җәмәгать транспорты тукталышларыннан җәяү чыгу мөмкинлеге булу күзлегеннән гражданнар өчен уңайлылыклар тәэмин итәргә тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең, шул исәптән инвалид коляскаларда хәрәкәт итүче, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага керү мөмкинлеген тоткарлыксыз тәэмин итү максатларында, инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, пандуслар, поручнялар, тактиль (контраст) кисәтү элементлары, инвалидларга тоткарлыксыз үтеп керүне һәм инвалидларны хәрәкәтләндерүне тәэмин итәрлек башка махсус җайланмалар белән җиһазландырыла.

Вәкаләтле орган бинасының үзәк керү урынына түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган табличка (вывеска) урнаштырылырга тиеш:

исеме;

урнашу урыны һәм юридик адресы;

эш режимы;

кабул итү графигы;

Белешмәләр өчен телефоннар номеры.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар санитар-эпидемиологик кагыйдәләргә һәм нормативларга туры килергә тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар түбәндәгеләр белән җиһазландырыла:

янгынга каршы система һәм янгын сүндерү чаралары; гадәттән тыш хәл барлыкка килү турында хәбәр итү системасы; килүчеләр өчен бәдрәф бүлмәләре.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү залы урындыклар, эскәмияләр белән җиһазландырыла, аларның саны факттагы йөкләнештән һәм аларны бинада урнаштыру мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнә, шулай ук мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

Мәгълүмати стендта урнаштырылган материалларның текстлары уку өчен уңайлы шрифт белән, төзәтүләрсез, иң мөһим урыннарны ярымкалын шрифт белән аерып чыгарыла.

Гаризалар тутыру өчен урыннар урындыклар, өстәлләр (стойкалар), гаризалар бланкалары, язу әсбаплары белән җиһазландырыла.

Мөрәҗәгать итүче өчен кабул итү урыннарына түбәндәге күрсәтмәләр белән мәгълүмати табличкалар (вывескалар) урнаштырыла:

кабинетның номеры һәм бүлекнең исеме;

фамилияләре, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булган очракта),

документларны кабул иткән өчен җаваплы зат вазыйфасын;

мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү графигы.

Документлар кабул итү өчен һәр җаваплы затның эш урыны, мәгълүматны кирәкле мәгълүмат базаларына, басма җайланмага (принтерга) һәм күчерә торган җайланмага керү мөмкинлеге булган персональ компьютер белән җиһазландырылган.

Документлар кабул итү өчен җаваплы кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта) һәм вазыйфасы күрсәтелгән өстәл табличкасы булырга тиеш.

Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектка (бинага, бинага) тоткарлыксыз кереп йөрү мөмкинлеге;

муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар һәм бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шулай ук мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән коляска креслосын кулланып;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясенең нык тайпылышы булган инвалидларны озата бару;

инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга һәм бүлмәләргә һәм тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәткә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешле урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайль рельеф-ноктaлы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау;

сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

эт-проводникны, аны махсус укытуны раслый торган документ булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган объектларга (биналарга, бүлмәләргә) кертү;

инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән беррәттән муниципаль хезмәтләр алуга комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

.

**Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре**

2.21. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалануның төп күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гомуми файдаланудагы мәгълүмат телекоммуникация челтәрләрендә (шул исәптән «Интернет» челтәрендә), массакүләм мәгълүмат чараларында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе, сроклары һәм барышы турында тулы һәм аңлаешлы мәгълүмат булу;

муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән ЕПГУ һәм / яки РПГУ кулланып;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль белем бирү оешмасында урын бирү эзлеклелеге турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән ЕПГУ һәм/яки РПГУ кулланып.

2.22. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатының төп күрсәткечләре түбәндәгеләр була:

муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге Административ регламентта билгеләнгән стандарты нигезендә үз вакытында күрсәтелүе;

гражданның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләр саны минималь мөмкин булган саны; . . ;

хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр һәм аларның мөрәҗәгать итүчеләргә карата әдәпсез (игътибарсыз) мөнәсәбәттә булмавы;

Вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү барышында билгеләнгән срокларны бозмау;

Вәкаләтле органның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына), аның вазыйфаи затларына муниципаль хезмәт күрсәткәндә кабул ителә (кылына) торган (кылган) хезмәт күрсәтүләрне карау йомгаклары буенча мөрәҗәгать итүчеләр таләпләрен канәгатьләндерү (өлешчә канәгатьләндерү) турында карарларда чыгарылдырылган дәгъваларны белдерү турында гаризаларның булмавы.

**Күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен, экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алган башка таләпләр**

2.23. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү ЕПГУ һәм/яки РПГУ аша гаризалар бирү һәм күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.24. Мөрәҗәгать итүчеләргә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле гаризаны, документларны һәм белешмәләрне ЕПГУ һәм/ яки РПГУ аша электрон формада җибәрү мөмкинлеге тәэмин ителә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен мөрәҗәгать итүче ЕПГУ һәм/яки РПГУга ЕСИА да хисап язмасы белән расланган шәхси зат ролендә (физик зат) авторизацияләнергә, муниципаль хезмәт күрсәтү атамасын күрсәтергә һәм тәкъдим ителгән интерактив гариза формасын тутырырга тиеш.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан гади электрон имзасы белән имзалана һәм Вәкаләтле органга СМЭВ аша җибәрелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең электрон формасы Вәкаләтле органның (оешманың) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган әлеге Административ регламентның 2.8.3-2.8.8 пунктларында каралган документларны электрон формада беркетү мөмкинлеген күздә тота.

Әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре мөрәҗәгать итүчегә ЕПГУ һәм/яки РПГУ дагы шәхси кабинетына гариза буенча хәбәрнамә рәвешендә җибәрелә.

Гариза ЕПГУ һәм/яки РПДУ аша җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе шулай ук мөрәҗәгать итүчегә кәгазь саклагычта Вәкаләтле органда, күпфункцияле үзәктә бирелергә мөмкин.

2.25. Әлеге Административ регламентның 2.8.3, 2.8.8 пунктларында каралган электрон документлар тапшырганда, ЕПГУ аша мондый документлар pdf, jpg, jpeg sig форматларында бирелә.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

- документтагы битләр санын һәм документларны идентификацияләү мөмкинлеге;
- тексттагы рәсемнәр һәм таблицалар буенча күчүне тәэмин итә торган өлешләр, бүлекләр, бүлекләр (бүлекләр) буенча структуралаштырылган мәгълүмат һәм билгеләрне үз эченә алган документлар өчен .

**III. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре**

**Административ процедураларның, формасына карамастан,тулы исемлеге**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм башка документларны кабул итү һәм теркәү;

;

СМЭВ аша белешмәләр алу;

документларны һәм белешмәләрне карау;

карар кабул итү;

арадаш нәтиҗәне бирү;
муниципаль хезмәтнең төп нәтиҗәсен юридик әһәмиятле язмалар реестрына кертү.

Административ процедуралар тасвирламасы әлеге Административ регламентка 11 нче кушымтада тәкъдим ителгән.

**Электрон формада ЕПГУ һәм / яки РПГУ аша дәүләт (муниципаль) хезмәтен күрсәткәндә административ процедуралар (гамәлләр) исемлеге**

.

3.2. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчегә өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алу;

электрон формада гаризаны формалаштыру;

электрон формада гаризаны карау барышы турында белешмәләр алу;

мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгате буенча башка рәвешләрдә бирелгән гаризаны карау барышы турында ЕПГУ да белешмәләр алу мөмкинлеге

;

муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашыру;

Вәкаләтле органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) йә Вәкаләтле органның муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затларының йә муниципаль хезмәткәрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

**Хезмәт күрсәтү формасына карамыйча, административ процедураларны (гамәлләрне) гамәлгә ашыру тәртибе**

3.3. Гаризаны формалаштыру.

Гариза ЕПГУ һәм / яки РПГУ дагы электрон рәвештә формалаштырылырга яки кәгазь саклагычта тапшырылырга мөмкин.

Электрон формада гариза формалаштыру, кәгазь саклагычта гариза тапшырыну таләп итми.

Мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасында һәр юлны тутырганнан соң, формалаштырган гаризаны формат-логик тикшерү башкарыла. Электрон гариза формасындагы юллар дөрес тутырылмаганлыгы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон гариза формасында мәгълүмати хәбәр ярдәмендә җиткерелә.

ЕПГУ һәм / яки РПГУ га гариза биргәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта электрон формага кертелгән гаризаны саклап калу, шул исәптән кертү хаталары барлыкка килгәндә һәм күрсәткечләрне гаризаның электрон формасына кабат кертү өчен кире кайтару;

б) мөрәҗәгать итүченең ЕСИА профилендә урнаштырылган белешмәләр нигезендә электрон формасы кырларын автомат рәвештә тутыру мөмкинлеге;

в) элек кертелгән мәгълүматын югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

г) мөрәҗәгать итүченең ЕПГУ һәм / яки РПГУ га элегрәк ЕПГУ һәм / яки РПГУ га бирелгән гаризаларына керү мөмкинлеге.

ЕПГУ һәм / яки РПГУда формалаштырылган гариза СМЭВ аша мәктәпкәчә белем бирү буенча һәркем файдалана алырлык төбәк мәгълүмат системасына (алга таба - РГИС ДДО) җибәрелә.

3.4. РГИС ДДО кергәннән соң, электрон гариза Вәкаләтле органның гаризаны кабул итү һәм теркәү өчен җаваплы вазыйфаи заты (алга таба – җаваплы вазыйфаи зат) өчен

файдалана алырлык була. Шул вакытта мөрәҗәгать итүчегә ЕПГУ һәм / яки РПГУ га "Гариза мәктәпкәчә белем бирү буенча һәркем файдалана алырлык төбәк мәгълүмат системасына тапшырылган", дип хәбәрнамә җибәрелә. _____________ гариза теркәлгән.(гаризаны түбәндәге форматта теркәү датасы һәм вакыты күрсәтелә: ДД.ММ.ГГГГГГ:мм:сс) ______________номеры белән (*төбәк мәгълүмат системасында гаризаның уникаль номеры күрсәтелә)*. Гариза карауны 7 көн эчендә көтегез».

3.5. Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи заты ЕПГУ һәм/яки РПГУ дан кергән электрон гаризаларның булуын көненә кимендә 2 тапкыр тикшерә.

3.6. Вәкаләтле органның җаваплы вазыйфаи заты түбәндәгеләрне тәэмин итә:

а) гариза биргән вакыттан алып 1 эш көненнән дә соңга калмыйча, ә эш көне булмаган яисә бәйрәм көнендә кергән очракта, икенче эш көнендә дәүләт (муниципаль) хезмәтен күрсәтү турында гариза кабул итүне. Шул вакытта мөрәҗәгать итүчегә ЕПГУ һәм / яки РПГУ га "Гариза карала башланды" дигән хәбәрнамә җибәрелә.

